Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №X-9**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 28 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында

“Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 маддәсендәге 1 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетын административ комиссия төзүгә вәкаләтле орган итеп билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына:

Административ комиссия төзергә;
Административ комиссия составын расларга;
Административ комиссиянең эш регламентын расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка игълан ителгәннән) соң үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырып игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Ф.Г. Әхмәтҗанова